ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.08.2020 ел Баулы шәһәре №154

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 30 сентябрендәге 281 номерлы карары белән расланган Региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектын урнаштыру һәм бу хакта мәгълүмат җиткерү турында документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 30 сентябрендәге 281 номерлы карары белән расланган Региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектын урнаштыру һәм бу хакта мәгълүмат җиткерү турында документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

1.4 пункттагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы карары белән;

1.4 пункттагы тугызынчы абзацны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районының
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров